ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДАЧНЫЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Дачный авылы, Үзәк ур., 34

СОВЕТ ДАЧНОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район
п. Дачное, ул.Центральная, 34

Тел./факс: +7(84365) 78-3-33, e-mail:Dach.Vsg@tatar.ru


**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**29 май 2020 ел** **№ 174**

**Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге Советының 2018 елның 29 ноябрендәге 108 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дачный авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешма идарәсендә бушлай нигездә катнашуга яисә аның коллегиаль идарә органы составына керү өчен яллаучы (эш бирүче) вәкиленнән рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында» карарын гамәлдән чыгару турында**

2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 48 статьясының 1 өлешенә, «Дачный авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дачный авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Гамәлдән чыгарырга:

Дачный авыл җирлеге Советының 2018 елның 29 ноябрендәге 108 нче номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дачный авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешма идарәсендә бушлай нигездә катнашуга яисә аның коллегиаль идарә органы составына керү өчен яллаучы (эш бирүче) вәкиленнән рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында»гы карарын.

Дачный авыл җирлеге Советының 2019 елның 28 маендагы 126 нчы номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дачный авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешма идарәсендә бушлай нигездә катнашуга яисә аның коллегиаль идарә органы составына керү өчен яллаучы (эш бирүче) вәкиленнән рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турындагы карарына үзгәрешләр кертү турында» карарын.

2. Әлеге карарны Дачный авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль

берәмлекләре порталы составында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Р.А.Жильцов